ГЛАВА ШАДЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар  Постановление

“19 ” октябрь 2020 ел.  № 9

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Шәдче торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәдче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Шәдче авылы , Яшьләр урамы , 18 нче йорт адресы буенча урнашкан Шәдче авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 6 нчы ноябре 13.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Шәдче авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Шәдче авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Шәдче авылы торак пунктындагы Мәктәп урамы юлларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Шәдче авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);

- Шәдче торак пунктына урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү).

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башкарма комитетына Шәдче авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге башлыгы: В.В.Шрыков